КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 август г.Казань № 776

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт – Ак Барс» яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе өчен Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2021ел, 09 сентябрь, 853 нче карары белән расланган Кара диңгез яры буендагы шәһәр яны ял лагерындагы юнәлешле сменада һәм төрле тематик юнәлештәге сменада Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтмәләр коэффициентын 2022 елның 1 июненнән Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт - Ак Барс» яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе өчен 1,50439 күләмендә билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин